# «Вперёд – в прошлое 2012!»

## Промежуточный этап «Визитка»

Название работы: «Мой родной край».

Работа команды «Следопыты»

МБОУ «Мало-Уруссинская ООШ» Ютазинского муниципального района Республики Татарстан.

Руководители: Мухаммадиева Д.З., Саитова Г.Р., Галимова Р.З. учителя начальных классов .

Ютазы районы Татарстан Республикасының көньяк – көнчыгышында Башкортстан чиге янында урнашкан. Район 1991 елның 6 апрелендә Баулы районыннан аерылып чыгарылып яңадан төзелә.



2011 елда район үзенең 20 еллык юбилеен бәйрәм итте. Район үзәге – Уруссу бистәсе. Ютазы районы урманнарга,кырларга гына бай дип булмый, аның иң олы байлыгы – кешеләр.



Без Кече Уруссу авылында яшибез. Авылыбыз районнагы иң матур авылларның берсе. Кече Уруссу авылы 1923 елда оешкан. Безнең авыл урманнар уртасында яшеллеккә күмелеп утыра.





Кече Уруссу авылы кергән Ташкичү җирлегеннән Бөек Ватан сугышына 360 кеше китә. 148е сугыш кырында ятып кала. Авыл уртасына алар истәлегенә һәйкәл куелган.





Авыл уртасында яңа мәктәп балкып утыра. Ул 2001 елда төзелгән. Безнең мәктәптә 49 бала укый. Яңа, җылы, матур мәктәбебез белән без горурланабыз. Мәктәп алдына куелган Г.Тукай һәйкәле безне тырышып белем алырга өндәп тора.







Мин, Зарипова Зәринә Ринат кызы, Кече Уруссу авылының Пионер урамында яшим. Урамыбыз бик матур, Каенлык урма-нына терәлеп тора. 2нче сыйныфта укыйм. Җырларга, биергә яратам.

Мин, Султанова Рәлия Рәвис кызы, Чик-Бүләк урамында яшим. 1нче сыйныфта укыйм. Җәй көнендә урамыбыз яшеллеккә күмелә. Яшел чирәмдә тәгәрәп, менә шулай матур булып үсәм мин.



Ә без Алия белән Гөлия Хәкимовалар. 3нче сыйныфта укыйбыз. Биергә, җырларга яратабыз, бассейнга йөрибез. Кул эшләренә дә вакыт табабыз. Безнең авылда бик матур мәчет тә бар. Анда без дин сабаклары алабыз, гарәпчә язарга өйрәнәбез.



